# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Янгын куркынычсызлыгы турында" Татарстан
Республикасы Законына үзгәреш кертү хакында

"Янгын куркынычсызлыгы турында" Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993 ел, N 11-12) шуннан соңгы үзгәрешләр белән (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1994 ел, N 1-2 һәм Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1996 ел, N 2) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

44 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"44 статья. Янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә салым ташламалары

Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының Янгынга каршы дәүләт хезмәте идарәсе һәм бүлекчәләре органнары Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән вазыйфаларын үтәгәндә, Россия Федерациясе Пенсия фондына, Россия Федерациясе Социаль иминләштерү фондына, Россия Федерациясенең Халыкны эш белән тәэмин итү дәүләт фондына һәм мәҗбүри медицина иминләштерүе фондларына түләнүче иминлек кертемнәреннән гайре, тиешле бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга Янгынга каршы дәүләт хезмәте хезмәткәрләренең эш хакы күләменә карата билгеләнгән барлык төр салымнардан, җыемнардан, пошлиналардан һәм башка түләүләрдән азат ителә.

Янгыннан саклану предприятиеләренең һәм янгыннан саклану буенча җәмәгать оешмаларының янгын-техник продукция җитештерүдән, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр башкарудан һәм хезмәт күрсәтүдән килгән табышларына һәм керемнәренә законнар нигезендә салым салынмый.

Янгыннан саклану предприятиеләренен һәм янгыннын саклану буенча җәмәгать оешмаларының салым салынучы табышы түбәндәге суммаларга киметелә:

янгын-техник продукция житештерүне оештыруга һәм (яисә) сатып алуга юнәлдерелгән суммага;

янгыннан саклану хезмәтен тоту чыгымнарына;

"Янгын куркынычсызлыгы" исәбенә күчерелүче кертемнәр һәм иганәләр суммасына.

Өсталгән бәяләргә салым түләүдән законнар нигезендә түбәндәгеләр азат ителә:

янгын-техник продукция;

янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр;

янгын-техник продукция җитештерү, янгын куркынычсызлыгы өлкәсендә эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтү өчен сатып алынган материаллар, приборлар һәм җиһазлар.

Законнар нигезендә түбәндәгеләргә салым салынмый:

янгыннан саклану хезмәте файдалана торган җирләргә; гражданнарның һәм хокукый затларның янгыннан саклану хезмәтенә милек итеп (файдалануга) бушлай тапшырылучы акчаларына һәм мөлкәтенә;

Янгынга каршы дәүләт хезмәте предприятиеләренең һәм янгыннан саклану җәмәгать оешмаларының янгынга каршы максатларга юнәлдерелгән керемнәренә;

иминләштерү оешмаларының "Янгын куркынычсызлыгы" исәбенә юнәлдерелгән түләүләренә.

Республика янгынга каршы ирекле җәмгыяте янгын куркынычсызлыгы өлкәсендәге эшчәнлек (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) төрләре буенча лицензия җыемнарыннан азат ителә.

Дәүләт хакимияте һәм идарәсенен җирле органнары, җирле үзидарә органнары үз вәкаләтләре чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә кызыксындыручы өстәмә ташламалар билгеләргә хокуклы."

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1996 елның 21 ноябре
N 853